ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь, 2025 ел № 44/8

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Шәһәр Советы карары проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен карап, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 47, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13, 2019 елның 6 декабрендәге 34/14, 2020 елның 17 июнендәге 40/3, 2020 елның 29 декабрендәге 4/7, 2021 елның 27 маендагы 7/6, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5, 2022 елның 23 июнендәге 15/6, 2022 елның 26 декабрендәге 19/7, 2023 елның 5 маендагы 23/4, 2023 елның 25 октябрендәге 27/8, 2024 елның 2 маендагы 33/7,

2024 елның 6 декабрендәге 39/8 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **9 статьяның 1 өлеше 13 пунктында** «өстәмә белем бирүдән тыш),» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә;

2) **41 статьяда:**

а) **9 өлешнең 22 пунктында** «, җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында урнашкан парковкалардан (парковка урыннарыннан) түләүле нигездә файдаланган өчен,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) **14 өлештә түбәндәге эчтәлектәге** 2.1 пункт өстәргә:

«2.1 муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,»;

3) **59 статьяның 6 өлешендә** «гамәлгә куючыларының берсе» сүзләреннән соң «һәм гамәлгә куючысы», «массакүләм мәгълүмат чарасын» сүзләреннән соң «һәм челтәр басмасын.» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге Карар рәсми басылган көннән үз көченә керә.

3.Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2025 елның 4 июлендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU163020002024001.